Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...

# Кумәк көч

ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 46 (10686)
Чәршәмбе,
16 ноябрь 2016 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы эшчеләр бистәсе, Пионерская урамы, 30)

# КЫШЛАТУДА КИРТӘЛӘР БУЛМАС





Районыбыз хуҗалыкларының терлекчелек тармагында кышлату бара. "Бахтеевка" производство кооперативында да бу җаваплы чорга тулаем зур әзерлек белән керделәр.



Бу хуҗалыкта 1635 баш мөгезле эре терлек бар. Шуларның 500 се савыла торган сыерлар һәм 150 баш тана тәшкил итә. Хуҗалык агымдагы елның 10 аенда сыерлардан 410 баш бозау алган һәм бу сан 2015 елга карата 12 башка артык дигәнне сөйли. Октябрь аенда һәр баш үрчем терлектән уртача 486 грамм артым алынган.

Ун ай эчендә шулай ук һәр сыерга 2062 килограмм сөт җитештерелгән. Октябрь аенда һәр сыер исәбенә тәүлеккә 3,83 процент майлылык белән 5,5 килограмм сөт савылган.

Бу хуҗалыкта эшләрнең уңай баруына карап сокланасың да, ирексездән күз алдына торгынлык еллары килеп баса. Чөнки бүгенге көндә малларның саны да бихисап, терлек азыклары да мул итеп әзерләнгән.

- Терлекчелек тармагында гына бүген 55 кеше хезмәт итә, - дип сөйли "Бахтеевка" производство кооперативы директоры вазифаларын башкаручы Ирфан Рушанович Аюпов.

- Алар һәммәсе дә үзләренең тапшырылган участокларына зур җаваплылык белән карыйлар. Чөнки һәр кешенең хезмәт хакы тулаем эш нәтиҗәләре белән бәйле. Беренче сортка җитештерелгән продукциябезне көн аша (җаен һәр көн) Кузоватово районы җаваплылыгы чикләнгән «Вита» җәмгыяте килеп ала һәм аның өчен вакытында санаша. Ә бу исә эшчеләргә хезмәт хаклары бирүгә, хуҗалыкка кирәк-яракны, төрле җиһазлар алуга уңай мөмкинлекләр тудыра.

Моның нәтиҗәсендә Бахтеевка производство кооперативы соңгы елларда фермаларга камилләштерелгән сөт саву җиһазларын урнаштырган. Аны күрәсең дә, гаҗәпләнәсең-сыер савучылар электкеге еллардагы кебек кулларына чиләкләр элеп, сөтне тиешле урынга ташымыйлар, ул торбадан төрле фильтрлар аша сөт суыткычына ага. Савучыларның эш нәтиҗәләрен торбага эленгән махсус электросчетчиклардан күзәтеп була. Биредә үк электротитаннар су җылыта. Бу цехта оператор Александр Терносков хезмәт итә, ул эш беткәч үк, сөтүкәргеч торбаларны махсус эремә белән чистарта.

Икенче номерлы сөтчелек фермасында савучылар Ираида Васильева, Татьяна Кашкурова, Наталия Чагакова, Светлана Панфилова, Ирина Тюкаева, Екатерина Иванова, Зинаида Хурасева, Галина Ахмәдиева мул продукция алу өчен армый-талмый хезмәт итәләр. Биредәге коллектив белән ферма мөдирләре Т. А. Сидорова, О. В. Замалова җитәкчелек итәләр. Ирина Каримова - техник осеменатор, Александр Кирилов веттехник вазифаларын башкаралар.

- Терлекчелек тармагын алып баруда баш зоотехник Лидия Константиновна Панфилованың роле гаять зур, - дип дәвам итә сүзен И. Р. Аюпов.

- Бу өлкәдә аның 45 еллык стажы бар һәм олы яшьтә булуга карамастан, ул үзенең тәҗрибәсен башкалар белән дә бик теләп



уртаклаша. Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә, коллективыбызны яшь кадрлар белән тулыландырасы иде.

Бүген "Бахтеевка" производство кооперативында терлекләрне кышлату уңай темпта бара. Тиздән сыерлардан массалы рәвештә бозаулау көтелә, шул исәптән 150 баш тана да бозаулаячак, ә бу исә савымның артуы турында да белдерер.

Агымдагы елда хуҗалык маллар өчен: 461 тонна - коры печән, 3005 тонна - сенаж, 5748 тонна - силос, җитәрлек күләмдә фураж һәм башка азык берәмлекләре әзерләдә. Азыклар мул булып, җитәкчеләр тарафыннан хезмәт кешесенә игътибар, вакытында эш хаклары бирелсә, терлекләрне кышлатуда бернинди киртәләр булмас.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
**Автор фотолары.**

---

**АДМИНИСТРАЦИЯ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ "СТАРОКУЛАТКИНСКИЙ РАЙОН" УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ**

**Р А С П О Р Я Ж Е Н И Е**

09.11.2016 г. р.п. Старая Кулатка №103-р

О создании межведомственной комиссии по проверке внутридомового (внутриквартирного) газового оборудования жилищного фонда и объектов социальной сферы муниципального образования «Старокулаткинский район»

В целях предупреждения и обеспечения пожарной безопасности населения в населенных пунктах муниципального образования «Старокулаткинский район»:

1. Создать межведомственную комиссию по проверке внутридомового (внутриквартирного) газового оборудования и соответствия дымоходов и вентиляционных каналов жилищного фонда, а также на объектах социальной сферы, с включением в них представителей организаций, осуществляющих обслуживание внутридомового газового оборудования; организаций, обслуживающих многоквартирные дома, населенных пунктов муниципального образования «Старокулаткинский район»

2. Совместно с обслуживающим внутридомовое и внутриквартирное газовое оборудование Старокулаткинским эксплуатационным газовым участком разработать график внеплановых проверок. В первую очередь осуществить проверку многоквартирных домов, социальных учреждений и населения, входящих в группу «риска».

3. Распоряжение вступает в силу с момента подписания.

4. Контроль за выполнением настоящего распоряжения оставляю за собой.

**Глава администрации И.А.АБЛЯЗОВ.**

---

## ХӨРМӘТЛЕ ГАЗЕТА УКУЧЫЛАР!

**“Күмәк көч”кә язылу дәвам итә. Алты айга язылу бәясе – 349 сум 26 тиен.**

**Киләсе елда да бергә булыйк!**





---

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (17.11.) | ҖОМГА (18.11.) | ШИМБӘ (19.11.) | ЯКШӘМБЕ (20.11.) | ДҮШӘМБЕ (21.11.) | СИШӘМБЕ (22.11.) | ЧӘРШӘМБЕ (23.11.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| - 11 | - 5 | - 3 | - 4 | + 5 | - 9 | - 12 |
| - 7 | - 2 | - 2 | - 2 | + 2 | - 2 | - 14 |

КУМӘК КӨЧ
¹ 46, 16 ноябрь 2016 åë.

## ЯҢАЛЫКЛАР

Ульяновск өлкәсе Губернаторы Сергей Морозов консультатив комиссия һәм Дәүләт советы президиумының уртак утырышында катнашты. 12 ноябрь көнне Владимир Путин җитәкчелегендә Ярославльдә үткәрелгән киңәшмәдә катнашучылар Россия төбәкләренең инвестицион җәлеп итүчәнлеген күтәрү чаралары турында фикер алыштылар. Владимир Путин ассызыклаганча, бизнес өчен уңайлы шартлар тудыру - икътисадның тотрыклы үсеш темпларын һәм социаль өлкәнең үсешен тәэмин итә.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә укытучыларга үсеш региональ системасын эшләүгә керештеләр. Агымдагы елның октябрендә әлеге документны төзү инициативасы белән өлкә Педагогик палатасы чыгыш ясады. Губернатор Сергей Морозов аны хуплады. Регион Башлыгы билгеләвенчә, якындагы биш ел эчендә мәгариф системасын үзгәрешләр көтә. "Безгә биш ел дәвамында регионыбызда яшәүчеләрнең тормыш сыйфатларын күтәрүгә юнәлдерелгән өч типтагы реформаларны тормышка ашырырга туры киләчәк. Һәм иң беренче реформа, әлбәттә, мәгариф мәсьәләсенә кагылачак,"- дип билгеләде ул.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә авыл мәдәният йортларын этаплап ремонтларга ниятлиләр. Регионыбызда РФ Дәүләт советы һәм Президент каршындагы мәдәният һәм сәнгать Советы утырышында билгеләнгән күрсәтмәләрне үтәү буенча эшләр башкарыла. 2015 елдан башлап, регион стратегиянең төп максатларын тормышка ашыра." Барлык чыганаклар хисабына мәдәниятне финанслауны арттыру өчен Губернатор Сергей Морозов ярдәмендә Ульяновск өлкәсендә "Авыл мәдәнияты бишьеллыгы " партия проекты старт алды. 2016-2020 еллар дәвамында, әлеге проект кысаларында, шул исәптән " Җирле инициативалар ярдәме" программасы буенча авыл клубларын үстерүне дәвам итәчәкбез. Биш ел дәвамында, ел саен, төрле чыганаклардан килгән керемнәргә 50 авыл мәдәният йорты һәм 2020 елга барлык учреждениеләр норматив хәлгә китереләчәк", - дип сөйләде сәнгать һәм мәдәни сәясәт Министры вазифаларын башкаручы Татьяна Ившина.

● ● ●

Регионыбызда өлкә бюджетын икенче укылышта кабул итү буенча интенсив әзерлек эшләре дәвам итә. Өлкә Губернаторы С. И. Морозовның йөкләмәсе буенча барлык мөмкин булган иҗтимагый мәйданчыкларда фикер алышулар алып барыла. Бюджетны формалаштыру буенча "Бердәм Россия" фракциясе тарафыннан мөһим эшләр башкарыла. Аерым алганда, өлкә законнар чыгару Җыелышы депутатлары киләсе елга бюджет формалаштыру буенча регионның төрле тармак җитәкчеләре белән очрашулар үткәрделәр.

● ● ●

14 ноябрь көнне район мәдәният йортында яшь, талантлы, популяр автор-башкаручы Фирдүс Тямаев өч сәгать дәвамында искекулаткылыларга искиткеч тамаша күрсәтте. Моңлы җырчы сүз остасы буларак тамашачыларны үзенә җәлеп итте һәм симпатияләрен яулады. Залда утыручылар Фирдүснең һәр чыгышын кайнар алкышларга күмделәр.

ХОКУК БОЗУЛАРГА ҺӘМ АЛКОГОЛИЗМГА КАРШЫ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ

# КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫРГА ТЫРЫШЫЙК!



Иске Кулаткы район администрациясе каршында эшләп килгән хокук бозуларга һәм алкоголизмга каршы профилактикалау буенча комиссиясенең эшче төркеме үзенең вазифасын авылларга чыгып дәвам иттерде. Иске Атлаш авыл поселениесендә аның киңәйтелгән утырышы үтте. Район администрациясе Башлыгы вазифаларын үтәүче В.А. Деникаева әлеге чараны алып барды. Ул үзенең чыгышында алкоголь эчемлекләре файдаланган кешеләрнең куркыныч сыйфатта үлемнәрен, алкоголь аркасында гаиләләр таркалуы, эчүчеләрнең кешелек сыйфатын югалтулары турында сөйләде. Авылда әлеге начар гадәтләрдән һәм шушы юлга баскан халыкны коткарырга кирәклеген ассызыклап үтте. Әлбәттә, бирегә иҗтимагый оешмаларның роле зур. Алкоголизм чире йоккан кешеләрнең яшәү шартларын, андый аяныч хәлгә калу сәбәпләрен ачыклау белән бергә ул кешеләрне дәвалау, бу шартлардан коткару чараларын күрергә кирәк. Билгеле, начар гадәтләрне профилактикалау дәресләре мәктәптән ук башланырга тиеш, аннары мәдәният, медицина аны дәвам итә. Иске Атлаш урта мәктәбе директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары Н.Р. Чамкаевага, авыл культура йорты директоры Р.Я. Сыраҗетдиновага, участок больницасы табибы Р.А. Муллабаевага шушы хакта сораулар бирелде. Аларның бердәм булып начар гадәтләргә каршы көрәшүеннән дә күп нәрсә тора бит. Һәр кайсының үз бурычы, үз вазифалары бар. Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен тарату чараларын ешрак үткәрү үзенең уңай нәтиҗәсен бирми калмаячак, диде Венера Адельхановна.

Тик Иске Атлаш авылында профилактик чаралар тиешле дәрәҗәдә алып барылмый икән, моның турында Н.Р. Чамкаева үзенең чыгышында ачыктан – ачык сөйләде. Ул беренче чиратта ялган аракы сатучылар нокталарын бетерергә кирәк диген тәкъдим ясады. Аракы сатып торган нокталарның, полиция тарафыннан үткәргән кисәтүләргә карамастан, һаман да эшләп торуын билгеләде һәм кемнәр икәнлеген дә күрсәтте.

Комиссия әгъзалары утырышны тәмамлагач, аракы сатучы гаиләләргә, эчүчелек белән шөгыльләнеп яшәүче кешеләрнең өйләренә бардылар, аларның яшәү шартлары белән таныштылар. Аракы сатучыларның тормыш итүе ал да – гөл булса, хәмер эчүчеләр аяныч хәлгә калганлыгы күренде. Эчүчелеккә бирелгән кешеләр белән сөйләшеп тә алдылар. Эш юклыгы, гаиләләре булмавы яп – яшь кешеләрне аракы эчеп, шундый хәлгә калдыруы бер сәбәп булса, аларның сәламәт яшәү рәвешендә тәрбияләнмәүләре дә бүгенге хәлләрендә калдырган, бугай. Ә бит араларында кул осталары да бар, агачтан урындыкмы дисең, өстәлме, барысын да ясый беләләр. Район администрациясе Башлыгы вазифаларын үтәүче В.А. Деникаева авыру булганнарын участок больницасына дәваланырга салырга тәкъдим ясады. Шундый авыр ситуациядә калган кешеләрне җәзага тартырга гына түгел ә, бәлки, башта хәлләренә кереп, аңларга, дәваларга, ярдәм итәргә кирәктер. Чөнки алар да җәмгыятьнең шундый ук әгъзалары, мондый хәлгә калуда һәркайсыбызның гаебе бар.

**М. МАСИЕВА.**

2016 ЕЛ - ӨЛКӘДӘ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ЕЛЫ

# ТАТУЛЫККА НИ ҖИТӘ



Өлкәбездә барган Сәламәтлек саклау елы кысаларында медицина хезмәткәрләре төрле чаралар үткәреп, бу елга әһәмият бирәләр. Әле күптән түгел генә булып үткән авыл медицинасы хезмәткәрләре көнен Мосеевка авылында истә калырлык итеп билгеләп уздырдылар. Һөнәре буенча медицина туташы булган Асия Шәүкәт кызы Сабитова авылдагы фельдшер – акушерлык пунктында хезмәт иткән бүгенге көн ветеран медицина хезмәткәрләрен бергә җыеп, истәлекле чара уздырды. Алар арасында бик әдәпле, үз һөнәренә тугры калып, озак еллар халыкка хезмәт иткән ветераннар, әниләр, әбиләр бар иде. Һәркайсы турында сөйләп, үткәннәрне искә алып, җылы мөнәсәбәттә үтте бу чара. Күңелләргә җылылык өстәп Асия ханым моңлы итеп җырлар да башкарды. Аңа кушылып, кунаклар да татар халык җырларын җырлап, хисләргә бирелделәр. Бу чара 4 ноябрь – Халык бердәмлеге көнендә оештырылган иде. Авыл халкының бердәмлеге, татулыгы шундый кумәк чаралар белән дә ныгый.

**М. САНАТУЛЛИНА.**

РӘХМӘТ ХАТЫ

## «КҮМӘК КӨЧ» ҺӘР ӨЙДӘ БУЛСЫН!

«Күмәк көч» һәм «Өмет» газеталарын безнең районда мөселманнар бик яратып укыйлар. Чөнки халкыбыз алар аша районыбызның һәм өлкәбезнең яңалыклары белән якыннан танышып яшиләр.

Соңгы вакытта динебезнең тормышын яктыртуда бу басмаларның роле зур. Шуңа күрә аларны яздырып алу - һәр мөселманга бик мөһим.

Безнең районда 26 мәчет бар. Аларның һәммәсенең манараларыннан һәркөн моңлы азан тавышлары ишетелә. Мәчетләребездәге дин тормышы белән район Башлыгы Э. Ә. Ганеев һәрвакыт кызыксынып яши. Ул даими рәвештә үзенең хәләл малына мәчетләргә «Күмәк көч» һәм «Өмет» газеталарын рәсмиләштерә. Шушы изге гамәле өчен, без, район мөселманнары, «Күмәк көч» район газетасы аша аңа олы рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Рәхимҗан ФӘЙЗУЛЛИН,**
**Иске Кулаткы районы мөхтәсибе вазифасын башкаручы.**

**Совет депутатов МО «Старокулаткинский район» объявляет конкурс на замещение следующей вакантной должности:**

Председатель контрольно-счетного органа Совета депутатов муниципального образования «Старокулаткинский район». Требования к кандидату высшее профессиональное образование и не менее четырех лет стажа муниципальной службы (государственной службы) или не менее пяти лет стажа работы по специальности.

Прием документов осуществляется в здании администрации МО «Старокулаткинский район» 3 этаж, кабинет № 303, с 8.00 до 17.00 часов, обед с 12.00 до 13.00 часов.

Подача заявлений для участия в конкурсе возможна не позднее, чем за 20 дней после опубликования в газете «Кумяк кюч».

Конкурсная комиссия состоится 06.12.2016 года в малом зале здания администрации МО «Старокулаткинский район». Начало в 10.00 часов.

Конкурс проводится в форме конкурса документов и конкурса испытание.

**Справки по телефонам: 2-11-05.**

**РОССИЙСКАЯ ФЕДЕРАЦИЯ**
**Совет депутатов муниципального образования**
**«Старокулаткинский район»**
**Ульяновской области**

**РЕШЕНИЕ**

15.11.2016 г. р.п. Старая Кулатка № 3/1

**О назначении Главы администрации**
**муниципального образования**
**«Старокулаткинский район»**
**Ульяновской области**

В соответствии со статьей 37 Федерального закона от 06.10.2003 года №131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», пунктом 10 статьи 25 Устава муниципального образования «Старокулаткинский район» и по решению конкурсной комиссии по проведению конкурса на замещение должности Главы администрации муниципального образования "Старокулаткинский район» от 15.11.2016 года, Совет депутатов муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области

**РЕШИЛ:**

1. Назначить Главой администрации муниципального образования «Старокулаткинский район» Ульяновской области Аблязова Ильдара Адельшевича.
2. Настоящее решение вступает в силу с момента его подписания и подлежит официальному опубликованию.

**Глава**
**муниципального образования**
**«Старокулаткинский район»** **Э.А. ГАНЕЕВ.**

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

# ÊӨÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

*Повесть*

**Зифа Кадырова**




- Рушаниякәем, - Хәлимә тезләнеп Рушаниянең кулларына ябышты, - соңга калдың, сөйләшә дә алмадык. Дөнья хәлен белеп булмый, балаларымны ярдәмеңнән ташлама. Син миңа туганым кебек якын, кызганыч, элегрәк очрашмадык. Ишетәсеңме, ташлама, изгелегең җирдә ятып калмас. - Үрелеп Рушаниянең яңагыннан үпте. - Лилиямне сакла.

Ак халатлы ике шәфкать туташы Хәлимәне ике яктан култыклап алдылар, ачулана-ачулана алып чыгып киттеләр. Барысы әллә төш, әллә өн, аңларлык түгел иде. Ак яулыклы әби авызын яулык чите белән каплап:

- Ай, Аллам, ник кире кердең, балам? Ходаем, хәерең белән, мәрхәмәтеңнән ташлама баламны, үзең сакла. Дүрт баласы хакына. Кирәгем булса, мине ал, мин инде ашарын ашаган, яшәрен яшәгән, бала кайгысы күрсәтмә, Ходаем. Күп күрдем, күргәннәре дә җитәрлек.

Лилия Рушания апасының иңенә борынын төртеп, мышык-мышык елый, ак яулыклы әби аңлашылмаган телдә догалар укый. Рушания селкенә дә алмый утыра, болар барысы бер куркыныч төш кебек, котылып та, уянып та булмый торган.

- Чү, балалар, елатмагыз, яхшыга гына юрыйк, алдан кабер казымыйк. Әби җитез генә борылып, Рушаниянең маңгаена кулын куйды.

-Кан басымың күтәрелде, ахрысы, янасың. Кая соң бу табиблар? Лилия, бар, тизрәк, берәрсен дәш, кереп карасыннар, Рушания апаңның кан басымын үлчәсеннәр. Син, балам, ят тыныч кына, борчылма. Алла теләсә, барысы да яхшы булыр.

Рушания ишетте дә, аңлады да, тик тел әйләндереп сүз әйтә алмады. Бу кечкенә ак яулыклы әби аның Айбикә әнисен хәтерләтте. Ул да шундый көчле рухлы, сабыр, күркәм, аның янында тыныч һәм рәхәт була торган иде, ул гына шундый итеп юата белә иде. Рушания, әйтерсең, бала чагына кайтты, әби күрсәткән урынга сузылып ятты да, каядыр төшеп югалды. Аңа шундый рәхәт булып китте, аны әбисе иңбашыннан сөйде, әллә нинди матур сүзләр әйтте. Сүзләр өзек-өзек кайдандыр ишетелделәр, бөтен нәрсә әйләнде дә болганды. Рушания көч-хәл күзләрен ачты, каршысында утырган; ак калфаклы табибын күреп, аптырап карап ятты.

- Рушания ханым, хәлегез ничек, сез мине ишетәсезме? Карагыз әле миңа, сезгә ял кирәк. Без хәзер сезгә йокы даруы кадыйбыз да, сез тынычлап йоклыйсыз. Мин сездән үтенеп сорыйм, артык хискә бирелмәгез, бу сезгә бик тә зыянлы, сөйләштекме? Сез бүген беркая да бармыйсыз.

- Юк, миңа кайтырга кирәк, мине эзләп чыгачаклар, зинһар кайтарыгыз. Хәлимә кая, аның хәле ничек?

Илья Ильич бераз нидер уйлап утырды.

- Сезне монда калдырырга ярамый, сез хәзер әзрәк ял итегез дә минем янга керерсез, тагын да нишләргә икәнен сөйләшербез.

Рушания үзе дә сизмәстән авыр йокыга талды, ахрысы, укол ясап өлгергәннәр иде инде. Ул уянганда палатада ут яна, ниндидер таныш булмаган кешеләр буш койкаларга урнашканнар. Рушания аптырап торып утырды, ак яулыклы әби дә, Лилия белән Хәлимә дә юклар иде. Таныш булмаган кешеләр артларына борылганнар да, тып-тын гына яталар, ахрысы, аларның да үз кайгылары үзләренә җитәрлек. Рушания табиблар утыра торган кабинетның ишеген шакыды да, ишекне ачып карады, анда берәү дә юк иде. Нәрсәдер язып утырган шәфкать туташы янына килде.

- Сабированы операциядән кайчан алып менәләр?

- Өченче көнгә генә, ике көн реанимациядә торалар. Захарова, менә бу даруларны үзегез белән алыгыз, өйдә эчәрсез, менә монда язылган, кайчан ничек кабул итәргә. Илья Ильич «алдагы ике көнне килмәсәгез дә ярый»,- диде.

- Ярый. Белмисезме, Сабированың хәле ничек икән?

- Белмим шул, безнең анда йөрергә вакыт юк.

- Рушания урамга чыкканда, кояш инде агачлар артына төшеп бара иде. Тышка чыккач, саф һавада башы әйләнеп куйды, егылып китүдән куркып, ишеккә сөялде, шулчак кемдер сак кына беләгеннән эләктереп алды.

- Сез бүген соңладыгыз, мин инде әллә миннән башка кайтып киткәнсезме, дип торам.

Рушания сөенеп елмаеп куйды, бу хәзер аның көндәлек таксие иде.

- Сез мине көттегезме? Рәхмәт инде, ничек кайтам дип борчылып тора идем, - дип ул аны култыклап алды, алар акрын гына баскычтан төштеләр. - Гафу итегез, күпме бергә йөрибез, мин сезнең исемегезне дә белмим.

- Самат булам.

- Самат,- нинди матур исем. Мин Рушания булам.

- Сезнең дә исемегез бик матур, дөресен генә әйткәндә, мин бик күп баш ваттым, маржамы, татармы дип, сез безнең башкорт ягына тарткансыз.

- Ә сез кайдан соң?

- Мин Уфа ягыннан, Иглинодан.

- Ә мин Инзирдән.

Алар елмаешып бер-берсенә карашып куйдылар.

- Бездә генә мондый чибәр кызлар үсә торган иде. Сез алайса Захаровның хатыны буласыз, мин бит беләм сезнең ирегезне. Ул элек мин эшләгән цехта начальник иде, күптән инде. Мин фатир алдым да, заводтан киттем. Менә бит тормыш, кемнәр генә очрамый безнең бу эштә.

- Ә сез кайдан беләсез безнең йортны?

- Беренчедән, безнең эшебез шул - таксист бит без.Аннан, Захаровны белмәгән кеше бик аздыр ул бу шәһәрдә. Рушания, ачуланмасаң, бернәрсә сорыйм әле, синең монда йөргәнеңне өйдә беләләрме?

- Юк, белмиләр, сез дә әйтмәссез, дип уйлыйм.

- Шулайдыр дип уйлаган идем. Ник әйтмисез, ул бит табибларның ниндие кирәк - барысын алдыгызга тезеп бастыра ала, ә сез, көн дә кача-поса шунда чаклы киләсез. Ә берәй вакыт кайта алмасагыз?

- Самат, әйтче, әгәр сез хатыныгызның рак белән чирләгәнен белсәгез, нишләр идегез?

- Алла сакласын, акылдан язарга була, үлмәсә ярар иде дип күзенә карап утырырга, тьфү-тьфү, Ходай күрсәтмәсен.

- Менә, күрәсезме, җавабын да үзегез бирдегез. Шуңа күрә мин әйтмим, син дә әйтмә. Килеп тә җиттек, рәхмәт, Самат. Бу икебезнең генә сер булып калсын. Минем әле өйдә дә җавап бирәсе бар. Ике көннән шалтыратырмын.

Рушания ике көн тыныч кына, өендә даруларын ашап, өй мәшәкатьләре белән буташты, акрын гына теплицасына чыкты. Яз җиткәнен сиздереп, кар астыннан беренче чәчкәләр дә баш күтәргән, теплица эчендәге тюльпаннар шау чәчкәдә утыра, монда җылы, пыяланы язгы кояш нурлары җылыта. Рушания өчен генә Саша ял итү почмагы ясаткан иде, анда иске йомшак креслолар, өстәл, хәтта самавыр белән чәшкәләр дә бар. Рушания шул йомшак креслога утырып, чәчкәләренә карап, сокланып елмаеп куйды. Нинди матурлар! Ничек рәхәт шулай бар нәрсәне онытып, гамьсез генә утыру. Алдашып каядыр чабасы юк. Теге көнне Саша бик ачуланды шалтыратмыйча көне буе югалып йөргәнгә. Кайтып керүгә килеп кочаклап алды:

- Котымны алдың, кайда йөрисең болай? Эзләмәгән җирем калмады, бөтен кабинетны ачып карадым, юксың. Уйламаган уй калмады...

- Ни сөйлисең, Саша, миңа ни булсын.

- Больницага салдыларммы, әллә урладылармы?

- Сашенька, кемгә кирәк мин, мин бит яшь кыз түгел.

- Раечка, бөтенесе белә - синең өчен мин соңгы ыштанымны да салып бирергә әзер, саграк бул. Әйдә, мин сиңа машина алам, бер шофёр бирәм, кайда кирәк - шунда йөр, минем дә җаным тыныч булыр.

- Кирәкми, мин аена бер чыгам өйдән, көннекә ул кеше нишләп утырсын?

Әлегә менә шулай котылды, башка көнгә тагын ни уйлап табарга? Ике көн үтте дә китте, кичтән ире эштән кайтты.

- Мин бер-ике көнгә Мәскәүгә китәм, эчке кием белән бер-ике күлмәк тә сал әле.

Сашаның китүенә ул сөенде генә. Рушания һәрвакыттагыча сәгать тугызга больницага килеп җитте. Хәлимәне реанимациядән күтәрсәләр, кәтәдер, аны сагынып та өлгергән бугай, ул аңа хәзер сеңлесе кебек якын иде. Рушания палатага килеп кергәндә, бер аның койкасы гына буш иде. «Тагын өлгермәдем, алып чыкканнар бит, йокласа уятмыйм», - дип, акрын гына аяк очына басты, тик монда бөтенләй башка кеше ята иде, Рушания сискәнеп китте.

- Хәлимә кая, монда Хәлимә ята иде бит?

- Белмим, мин килгәндә буш иде бу койка, - диде олы гына яшьтәге хатын.

Рушания сорарга дип коридорга чыкты, ишектән чыгу белән Илья Ильич белән борынга-борын диярлек килеп төртелделәр.

- Хәлимә кая? - диде курку катыш дулкынлануын яшерә алмыйча.

- Ә без аны икенче больницага күчердек, - диде күзләрен яшереп.

- Кайсы больницага, ник күчердегез?

- Казанга. Сезгә тыныч булырга кирәк, әйдәгез, сезнең хәзер капельницага ятасыгыз бар. Ул аны иплэп кенә култыклап алды, артык сөйләшми генә үз палатасына кертеп яткырды.

- Бер дүрт сәгатьләп тыныч кына ятыгыз, бу даруны шулай көн аша алырсыз. Сез бик тиз хискә бирелүчән, бу дәвалауга бик комачаулый, бер алга, ике артка тартасыз. Монда күргәннәрнең барысын да алай бик якын йөрәгегезгә алмагыз, шуңа күрә мин сезгә көн аша йөрергә рөхсәт итәм. Бер көн өйдә дарулар эчәсез, икенче көнне капельница килеп аласыз.

Яшь табиб, шәфкать туташы энәләрне урнаштырып бетергәнче, берсүзсез күзен алмыйча Рушанияне күзәтте. Никтер бу хатын үзенә магнит урынына тартты, караган саен карыйсы килде, шушы тамчылар тамып беткәнче берсүзсез янында утырасы иде. Тик сораулар гына бирмәсен, җаваплары аны аяктан егуы бар. Теге көнне аны йоклаткач, ул берничә тапкыр кереп бик озак сокланып карап торды. Аның болай үз пациентларына беркайчан гашыйк булганы юк иде әле. Ник соң ул шушы утыз бишкә җиткәнче пар тапмый йөри? Ә монда ун яшь аерма, тик ул аерманы никтер сизми, көннән-көн күңеленә ныграк керә, уйландыра һәм борчыла. Рушания үзендә чит карашлар тоеп, кинәт борылып карады, аяк очында басып торган табибның уйчан карашлары белән очрашты. Алар, сүзсез аңлашырга теләгәндәй, бик озак бер-берсенә карашып тордылар. Рушаниянең карашында аптыраш, ни әйтергә уйлый тагын? Илья кинәт үзенең ни хәлдә басып торуын аңлап алды, читенсенеп ни әйтергә белми торды да, кырт кына борылып чыгып китте. Рушания да уйга калды, ни аңлата бу караш? Ул гына белә аның ни белән чирләгәнен, кызганамы, җәллиме? Хәер, ни аермасы бар? Ул еш тоя үзендә чит ир-ат күз карашын, тик яратмый иде үзен күз карашы белән ашаган кешене, бигрәк тә мәҗлесләрдә. Яннарында хатыннары утыра, ә алар оятсыз рәвештә аны күзләре белән капшыйлар. Моңа Сашаның да бик ачуы килә иде. Тик бу башка, аның карашында оятсызлык та, мыскыллау да күренмәде, димәк, эшләр шәптән түгел. Мин сорамыйм, ул әйтми. Тамчылар ашыкмый гына тама да тама, уйланып ятарга вакыт та җитәрлек, тик уйлаган саен очы-кырые күренми. Әгәр аңарда да Люба чире булса, нишләргә, ничек яшәргә, ул моны белергә тиеш, ә белгәч нишләргә?

Рушания килде, кайтты, Лилия килер дип көтте, тик ул һаман күренмәде. Бүген дә күренмәгәч, үзе кереп чыкмакчы булды. Самат инде хәзер шәхси шоферына әйләнде, Рушаниягә да җиңел булып калды, ичмаса, бер сөйләшер кешесе бар. Ул аның хәлен яхшы аңлый иде, артык сорау да бирми, аның хәлен йөзеннән үк аңларга тырышкандай, сиздерми генә карап-карап ала. Якташлар чит җирдә туганнар кебек якын була, Самат та Рушанияне үз туганы кебек күрә башлады һәм аның өчен эчтән генә бик тә борчыла. Ул хәзер Рушаниянең бару-кайту вакытын чамалап, үз эшен аның буенча җайлады. Ул тәүлек буена шәһәрнең бер башыннан икенче башына чабып, кеше ташып акча эшләсә, хәзер беренче кайгысы Рушания якташы. Чакырткачы ук больница төбенә килеп утыра торган булды, гаиләсе дә белмәгәч, ул бердәнбер ярдәмче, аның хәлен аңлаучы кеше иде хәзергә. Кеше серен саклау зур җаваплылык, тик бу серне Рушания күпме саклый алыр соң? Ялгызың гына күтәрә торган чир түгел.

Самат ике тулуга больница төбенә килеп туктады. Тышта яз, кояш кыздыра, больница матур нарат урманы эченә урнашкан. Асфальтта эрегән кар күлдәвекләре җыелып ята, тургайлар шул күлдәвектә чыр-чу килеп су коеналар, килгән язга сөенәләр, күгәрченнәр дә пар сайлыйлар, гөр-гөр килеп куышып уйныйлар. Самат, исе китеп, нинди салкын кышларны җиңеп чыккан шушы кечкенә кошчык дөньясын күзәтте. Янына килеп баскан Рушанияне да күрмәде. Рушания бер кошларга, бер Саматка карап торды.

- Алар да язга исән чыгуларына сөенәләр.

Самат күтәрелеп карады, янында басып торган Рушаниянең йөзендә әйтеп бетергесез нур, соклану һәм берни булмагандай тынычлык. Аның түгәрәк йөзендә чак кына елмайган матур иреннәре балаларның әкият китабындагы матур итеп ясалган әллә тулы айны, әллә кояшны хәтерләтә иде. Самат күзен алмый карап торды, нинди бөеклек бу хатында, нинди балалардай самими чисталык, сөйкемлелек! Аңа карап нинди дә булса җенси пычрак уйлар түгел, киресенчә, сокланыр өчен генә бу җиргә яралган диярсең. Рушания да аның янына скамейкага килеп утырды, ул да чыр-чу килгән тургайларга карады.

-- Бу дөньяда бар тере җанда бер теләк - мәхәббәтеңне табу, гаилә кору, балалар үстерү. Кара инде бу кошчыкларны, аларда да шул теләк, юксаң, буй җитмәс хыял түгел.

- Рушания тагын нидер әйтмәкче иде дә, тукталып калды.

- Самат, минем азрак вакыт та бар, әйдә, минем бер танышларга гына кереп, хәлен белеп чыгыйк әле, аны операциядән соң Казанга күчергәннәр диделәр. Мин берни белмим, кереп балаларыннан гына сорап чыгыйм, син бераз гына көтеп торырсың бит?

Самат әйткән адрес белән килеп туктады. Рушания кызу атлап Хәлимәләр йортына ашыкты, бүген аңа ничектер җиңел иде йөрүе. Соңгы вакытта аның бөтен җире авырта, кузгалып китүе дә бик авыр иде, ә бүген, күз тимәсен, ул үзен бик рәхәт тойды, ахрысы, дәвалауның файдасы тия башлады. Рушания икенче катка җиңел генә күтәрелде, таныш ишекнең кыңгырау төймәсенә басты. Ишекне әлеге кечкенә кыз ачты.

- Исәнме, үскәнем, өйдә кем бар?

- Әби, апа.

Өйдә әллә нинди тынлык. Рушания алга атлады, эчке бүлмәнең тәрәзә төбендә дисбе тартып, ак яулыклы әби утыра, почмактагы караватта йомарланып кына Лилия йоклап ята. Рушания акрын гына:

- Исәнмесез, - диде. Карт әби ялт итеп борылып карады, исенә төшерергә теләгәндәй, бик озак аңа карап торды.

- Исән, балам, исән, - диде башын селкеп. - Сине кайдадыр күргәнем бар кебек.

- Без Хәлимә белән бергә идек.

- Рушания апа? - Кинәт Лилия сикереп торып утырды, елап шешенеп беткән йөзен күргәч, Рушаниянең кинәт йөрәге кысып куйды.

- Лилия, үскәнем, ни булды, ник елыйсың?

- Сез, сез монда ничек киләсе иттегез? Сез генә безне әнисез калдырдыгыз, сез генә гаепле. Ул теләмәде пычак астына ятарга, сез күндердегез.

- Чү, балам, алай ярамый, тынычлан, кем уйлаган бит менә болай булыр дип. Әби оныкларын тынычландырмакчы булды, каккан казык кебек басып торган Рушаниягә карады.

- Утыр, балам, утыр, Хәлимәм китте шул инде, китте.

- Әбекәй, ни сөйлисез, кая китте, миңа Казан больницасына күчердек диделәр.

- Ахирәт дөньясына, балам, урыны оҗмахта булсын. - Ак әби яулык очы белән яшьле күзләрен сөртте.

Лилия мендәренә капланып үксе-үксе елый, кечкенәсе почмакка сыенып күзләрен ышкый. Рушаниянең һич кенә дә башына сыеп бетә алмады. Моның булуы мөмкин түгел, үз аяклары белән кергән кеше. Рушания кинәт чайкалып куйды, бөтен дөнья әйләнде, һава җитмәде, нәрсәдер буды, ул тизрәк һавага чыгарга дип, чыгу юлына борылды.

- Син генә үтердең әнине, - дип кычкырды артыннан Лилия.

- Чү, балам, кирәкми, ә син, Рушания балам, якшәмбе кил, җидесен укытабыз. Әби сөйләнә-сөйләнә Рушания артыннан иярде. - Син балаларга үпкәләмә, Хәлимәм бик ярата иде сине, инде Ходай сиңа терелеп чыгарга язсын.

Рушаниянең күзаллары караңгыланды, балалар алдында егылмастан, тизрәк һавага чыгарга тырышты. Стена буйлап әллә шуды, әллә атлады, ул берни аңламас хәлгә җитте. Тышкы ишекнең тоткасына ябышты, ачылган ишеккә ябышып, исерек кеше кебек болганды, кайда икәнен дә аңламый башлады, хәле тәмам бетеп, ишек буйлап шуып төшә башлады. Шулчак кемдер килеп күтәреп алды, нидер кычкырды, яңаклады. Керфекләре белән һавага ябышырга теләгәндәй, күзләрен ачарга тырышты. Аңы да, гәүдәсе дә аңа буйсынмады, ул бөтенләй камырга әйләнде, бөтен нәрсә әйләнеп-әйләнеп, һаваларга, ак болытларга алып менеп китте.

Подъезд ишегеннән Рушания күренгәч, Самат машинасын кабызды, тик Рушания ишектән китә алмады, ябышып торды да, акрын гына җиргә чүгә башлады. Самат машинадан сикереп төште, үзе дә ничек килеп тотып өлгергәнен сизми дә калды. Рушаниянең чырае ап-ак кәгазь төсендә, гәүдәсен дә тота алмый. Самат ике уйлап тормады, тиз генә машинага күтәреп салды да, кире больницага машинасын куалады. Ярый әллә ни ерак түгел иде. Кабул итү бүлмәсенең ишек төбенә терәлеп килеп туктады, ишек төбендә торган ниндидер кешегә кычкырды. Ишекне ачып, Рушанияне күтәреп алды да, кабул итү бүлмәсенә үзе күтәреп алып керде. Рушания аңсыз иде, аны каталкага салдылар да, каядыр йөгерттеләр. Самат та ияргән иде дә, тик аны үзләре кергән ишекнең теге ягына кертмәделәр. Аңа көтәсе генә калды. Машинада калган сумкасында кабат-кабат телефон шалтырады. Әллә дөресен әйтергәме, дип телефонны кулына да алып карады. Ә анда бер-бер артлы Саша, Игорь, Алеся шалтыратты.

Самат кайтып китмәде, берсүзсез машинасында көтеп утыра бирде. Инде караңгы да төште, ә Рушания һаман чыкмады да чыкмады. Ул ике күзен ишектән алмады. Урам баганаларында ут кабынды, кабул итү бүлмәсенең ишек алды яп-якты, ишек алдында ыгы-зыгы йөрүчеләр дә кимеде. Шулай да берәү чыгып бераз торды да, туп-туры аның машинасына таба килә башлады. Самат ни дә уйлап өлгергәнче, уртача буйлы, табиблар кия торган киемнән яшь кенә ир-ат килеп ишекне ачты.

- Рөхсәт итегез, миңа сезнең белән сөйләшергә кирәк.

- Утырыгыз, - диде Самат аңа борылып.

- Мин Илья Ильич булам, Захарованың табибы. Сез бит аны көтәсез, мин сездән сорамакчы идем, сез аның кеме буласыз?

- Дөресен генә әйткәндә, беркем дә түгел, мин таксист кына. Ә танышып-сөйләшеп киткәч, якташлар булып чыктык. Бик яхшы кеше, кызганыч менә монда йөрүе...

- Ә бүген нәрсә булды соң бу хәлгә төшәрлек?

- Моннан ерак түгел бер хатынның хәлен генә белеп чыгам, дип кереп киткән иде, шуннан чыкты да егылды.

- Аңлашыла. Ул хатын операция өстәлендә үлде. Аңа шулай тәэсир итәсен белдем, шуңа көн аша йөрергә куштым. Ничек тә саклап калырга тырыштым, булмады, өйләренә барыр дип һич тә башыма китермәдем. Ярый, сез бүген көтмәгез, кайтара алмыйм, хәзер йоклый ул.

- Карагыз, нишләргә соң инде, өендә эзлиләр бит, бәлки әйтергәдер, сез беләсезме аның ире кем икәнен?

- Юк, кем булса да, аның рөхсәтеннән башка ярамый. Мин каршы түгел, тик ул үзе бик каршы. Без әйткәнне белсә, тагын бер тетрәнү кичерәчәк, ә аның белән хәзер бик сак булырга кирәк, иртәгә күз күрер.

- Алайса, менә сумкасын алыгыз, эчендә телефоны. Ә шулай да, аның ире бик бай һәм бик зур кеше, даруның ниндие кирәк - таба, әллә кайларга алып барып дәвалый ала.

- Сез хәтерлисезме Горбачевны? Яшь табиб Саматка текәлде. - Ил башлыгы, ярты ил байлыгын биреп тә, хатынын коткара алмады. Минем дә беркемне дә үтерәсем килми, бөтен җир шары эзли аның дәвасын, тик ул бездән көчлерәк.

Ильяның эш сәгате бетеп кайтырга җыенып йөри иде. Кабул итү бүлмәсеннән шалтыратып, тиз төшәргә куштылар. Каталкада аңсыз яткан Захарованы күргәч, кинәт тезләре бөгелеп киткәндәй булды. Әле 30-40 минут элек кенә тәрәзәдән ул утырып киткән машинаны карашы белән озатып калды, һәрвакыт тыныч, сабыр холкы белән бергә эшләгән иптәшләре арасында аерылып торган, ни генә булганда да салкын канлы, аек акыл белән эш итә торган Ильяны да курку биләп алды.

**Дәвамы бар.**

кумәк көч
¹ 46, 16 ноябрь 2016 åë.

ИХТИРАМГА ЛАЕК ШӘХЕСЛӘР

# ЯЗМЫШ СЫНАУЛАРЫ АША ҮТКӘН ГОМЕР



Карамалы авылында гомер итүче Мәүҗүдә Низамовна Давыдова өчен дә ноябрь ае истәлекле. 90 ел элек ул шушы авылда дөньяга туа.

Әйе, 90 яшь - бик озын гомер кебек тоелса да, көндәлек эш-мәшәкатьләр белән бер мизгелдәй сизелми генә үтеп тә киткән. Иң мөһиме - ул бушка үтмәгән. Яшәү мәгънәсе балалар һәм оныклар тормышында да ачык чагылыш тапкан.

Бу көнне Мәүҗүдә апа янында һәрвакыттагыча балалары, оныклары булыр. Дүрт баласы, алты онигы һәм алты оныкчасы өчен чын мәгънәсендә зур бәйрәм. Йорт хуҗасы – улы Ринат һәм килене Рәйсәнең дә тынгысыз чагы. Алар барчасы да иң якын, иң газиз кешеләренә изге теләкләрен юлларлар.

"Һәр буын өчен язмышның үз сынавы. Безгә ул илнең бик тә авыр еллары, сугыш чоры белән туры килде. Ил белән бергә булдык, түздек, хезмәт иттек, якты өмет белән яшәдек, - дип сүзен башлап җибәрде хөрмәтле юбиляр.

Аңа, яшьтәшләре кебек үк, балачакның рәхәтен күрү татымый. Авыл мәктәбендә биш сыйныф белем алганнан соң, ул җиң сызганып эшкә керешә. Олылар белән бергә урып - җыюда, кәлтә бәйләүдә, ат җигеп салам, печән ташуда катнаша. Кече яшьтән үк әти-әнисенең ярдәмчесе булганга, бер эштән дә авырсынмый кыз бала.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Мәүҗүдә апа бер төркем авыл кызы белән район военкоматына чакырыла. Аларны Чапаевск шәһәренә юнәлтәләр. Бирелә ул хәрби заводта снарядлар ясау цехында хезмәт итә.

- Авыр булса да, һәрнәрсәгә шөкер итә белдек, язмыштан зарланмадык. Аллага шөкер, барысын да эшләдек, авыр дип тормадык. Барысы да киләчәк өчен дип башкарылды. Көн буе сузылган авыр хезмәттән кайткач, ашарга азык та юк иде, ләкин күңел күтәренкелеген, тормышка ышанычны югалтмадык, - дип сүзен дәвам итте Мәүҗүдә апа.

Туган авылына кайткач, ул Зеленай якларында окоп казуда катнаша. Илебезгә Бөек Җиңүне якынайтуда үзеннән зур өлеш кертә.

Сугыш тәмамлангач, Мәүҗүдә апа колхозда хезмәт итә башлый. Озакламый ул Муся исемле авыл егете белән гаилә корып җибәрә. Яшь гаиләне язмыш Асбест шәһәренә илтә. Ләкин туган җиргә мәхәббәт, авыл тормышын ярату үзенекен итә, 15 ел шәһәрдә яшәп, Мәүҗүдә апа белән Муся абый туган якларына әйләнеп кайталар.

Мәүҗүдә апа тормыш иптәше белән тигез тормышта дүрт балага: Фәриткә, Фәрүзәгә, Фәнимгә һәм Ринатка гомер бүләк итәләр. Бар көчләрен балаларны сәламәт, белемле, тәрбияле итү өчен куйган әти-әниләренең максаты да тормышка аша. Әлеге гаиләдән чыккан балалар бүгенге көндә үз гаиләләрен корып, үрнәк тормыш алып баралар.

Мәүҗүдә апа гомерен авыл тормышына багышлый. Колхозда, авыл правлениесендә намуслы хезмәт куя. Нинди генә эшләр йөкләмәсеннәр, ул барысын да җиренә җиткереп, күңелен биреп башкара. Озак еллар дәвамында бар көчен, тырышлыгын куеп, авыл тормышын алга җибәрүгә зур өлеш кертә. Карусыз хезмәте турында төрле елларда бирелгән күп санлы Мактау кәгазьләре, медальләре сөйли.

Тормыш иптәше белән бәхетле гомер кичергәнгә, Мәүҗүдә апа Муся абыйны бүген дә сагынып, юксынып яши.

Хәзерге вакытта олы юбиляр улы Ринат, килене Рәйсә, оныгы Алина тәрбиясендә бәхетле картлык кичерә. Читтә торучы бала-оныклары да әниләренең һәм әбиләренең хәлен һәрдаим белешеп, еш кына туган йортка кайталар. Чөнки анда күңелләренә иман нуры индерүче, яшәү мәгънәсен, яшәү ямен тояргa өйрәтүче газиз кешеләре - әниләре һәм әбиләре көтә. Балаларының, оныкларының һәр хәрәкәтендә, һәр сүзендә әниләренә һәм әбиләренә карата булган ихтирам, ярату хисләре ярылып ята.

- Әти-әни безгә җил-яңгыр тидерми үстерделәр, безнең өчен күп көч түктеләр. Әтигә генә бүгенге көннәрне күрергә язмады. Әни генә исән булып, озак еллар безне шатландырып яшәсен, без аның алдында баш иябез һәм олы рәхмәтләребезне белдерәбез, диләр балалары.

Гомеренең бушка үтмәвеннән канәгатьләнү хисе кичереп, юбилярның күңелләре нечкәрә, күзләренә яшьләр килә. Бүгенге тормышы белән Мәүҗүдә апа бик канәгать. Һәр туар таңга шатланып, саулыкның кадерен белеп, бала-оныкларына сокланып, бар нәрсәгә риза булып, тормыштан ямь табып яши.

Бәйрәм уңаеннан без дә Мәүҗүдә Низамовнаны олы юбилее белән котлыйбыз. Сез авыр да, мактаулы да тормыш юлы узгансыз. Барлык эш-гамәлләрегез, яшәү рәвешегез яшьләр өчен үрнәк булып тора. Барысы өчен дә зур рәхмәт Сезгә. Картлыгыгыз тынычлыкта үтсен. Ходай Сезне тән һәм җиһен саулыгыннан аермасын.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

# СЕҢЕЛЕМНЕҢ БӘЙРӘМЕ

*И хатын-кыз, син
уңган да,
һәм җитез дә,
өлгер дә.
Алтмыш яшең
тутырсаң да,
Син чибәрсең бүген дә.*

Минем фикеремчә, һәр кешенең әти-әнисеннән кала гомер буена бер сердәшчесе, иң якын туганы булырга тиеш. Иске Кулаткыда яшәүче сеңелем Асия Зәбировна Биктимерова - бу якты дөньядагы иң якын кешем. Ул минем генә түгел, энем Рифатьнең дә, Фуатьнең дә иң якын кешебез, кыз туганыбыз. Бу көннәрдә Асиябезгә 60 яшь тула. Бүгенге язмам да аның турында булыр.

Без, биш бала, әти-әниебезнең гаиләсендә, ямь-яшел каз үләне үскән, чиста урамлы ямьле Кирюшкино авылында туып үстек.

Ә Асиябезне арабызда иң уңганы, иң булганы дип йөртәбез. Ул, чыннан да, нәни чагыннан ук бик чибәр һәм зирәк бала булып үсте. Бераз олыгая төшкәч,



сәүдә системасында эшли башлады. Озак та үтмәде авылыбызның егете Мәкъсут Нәүмәнович Биктимеров белән матур гаилә корып җибәрделәр. Аларның гаиләләрен матурайтып, бер-бер артлы ике кыз һәм бер ир балалары туды. Алар әти-әниләренә бик ярдәмчел балалар булып үстеләр.

Еллар әкрен генә алга атлады һәм яраткан сеңелебез үзенең хезмәт биографиясен Госстрах челтәрендә дәвам итте. Намуслы хезмәте өчен күптөрле Почет грамоталары һәм Рәхмәт хатлары алуга ирешә. Бу бүләкләр аның тормышта үз юлын табуы турында ачыктан-ачык сөйли. Кешеләр белән нык элемтәдә булып, аралашып эшләгәнгә күрә, аны районыбызда бик күпләр яхшы беләләр.

Сеңелем Асия, минем дә иң олы терәгем, сердәшчем һәм булышчым. Аның балалары да миңа үз балаларым кебек якыннар.

Асиябез барлык эшкә дә бик өлгер, аның өе һәрвакыт пөхтә. Бакчасында да, өендә дә матур гөлләр үстерергә ярата. Аның бу шөгыле ирексездән, күкрәгенә кысып биш бала үстергән әниебезне исебезгә төшерә. Әниебез дә шулай тәрәзә төбендә гөлләр үстерергә ярата иде. Менә шундый хис - тойгылар астында шытып чыккан гөлләр кебек, минем күңелемдә дә түбәндәге шигъри юллар туды:

*Утыр әле, сеңелем,
яннарыма,
Искә алыйк, үткән
көннәрне.
Арасыннан әнкәй карап
торган
Тәрәз төбе тулы
гөлләрне.*

Киләчәктә дә безнең гомерләребез гөлчәчәкләргә төренеп шатлыкта, исәнлектә – саулыкта, бергә аралашып үтсен иде. Туачак таңнарыбыз тагын да матур итеп атсыннар һәм гомер көннәребезне гел якты, җылы кояш каршыласын иде.

Яраткан сеңелем, Асия! Юбилеең котлы булсын,!

**Кыз туганым**

*Кыз туганым, сиңа карап
сөенәм,
Син бит минем гомер
юлдашым.
Син дә, мин дә, чын татар
кызлары,
Саклыйбыз без татар
йоласын.
Кыз туганым, мин яратам
сине,
Әнием кебек хөрмәт
итәмен.
Синең белән сөйләшеп
утырсам,
Сагыш таралганын
сизәмен.
Кыз туганым, иң якыным
минем,
Бала чактан сине беләмен.
Син исәнлек, бәхет
телә миңа,
Мин дә сиңа шуны
теләрмен.
Кыз туганым, бер теләгем
сиңа,
Бул таяныч гомер кэземдә.
Бергә булсын ахыр
көннәребез,
Аермасын безне беркем дә.
Ә хәзергә тормыш тәмен
тоеп,
Пар канатлы булып
гомергә.
Татар дөньясында бизәк
булып,
Яшик әле, яшик без бергә.*

**Фатиха АХТӘМОВА.**
**Иске Кулаткы.**

# АЛДЫНГЫЛАР ДАНЛАНДЫ

Безнең Иске Кулаткы районының Почет тактасында һәр ел районыбызның хезмәт алдынгылары, җәмәгать тормышында актив катнашучылар данланалар. Бу почетлы урында һәр ел исемлекләр һәм фоторәсемнәр яңартыла.

Шушы очрактан быел 7 ноябрь көнне Иске Кулаткы район мәдәният йортында зур тантана булды. Әлеге матур чарада район администрациясе Башлыгы вазифаларын башкаручы В. А. Деникаева районыбызның ихтирамлы кешеләрен район Башлыгы




Э. Ә. Ганеев һәм үз исеменнән кайнар тәбрик итте һәм аларга Почет тактасында урын алулары турында таныклыклар тапшырды.

Искекулаткылылар Н. А. Кузаева, В. А. Сәйфуллина, Р. А. Шахутдинов, С. А. Абдуллина, Г. Н. Михеева, Р. Р. Абдрәхимов, Г. Я. Абдрәшитова, Г. А. Чукмарева, Р. Х. Ханбикова, В. В.Тимербулатова, Р. К. Биккулова, Ф. З. Тимушев, Р. М. Байбиков, И. Ф. Бадаева, И. Я. Мусин, Р. А. Магдеева, Т. Х. Караева, Ф. К. Зайкина, Ф. А. Ханбикова, Н. Д. Назиров, Ә. А. Тимербулатова, Л. Ф. Богданова, Р. С. Бәширов, И. Р. Сәйфуллин район Почет тактасы исемлегенә кертүгә лаек булдылар.

Ул көнне В. А. Деникаева шулай ук Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе укытучысы Р. А. Үмәрова Ульяновск өлкәсенең мәгариф һәм фән министрлыгының сертификатын, « Гөлчәчәк» балалар бакчасы тәрбиячесе Ә. Х. Ханбикова Рәхмәт хатын, Иске Кулаткы механика - технология колледжының укытучысы Г. К. Разаковага өлкә Губернаторы С. И. Морозовның Рәхмәт хатын һәм Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенең укытучысы Н. М. Абдрәшитовага район администрациясе Башлыгының Рәхмәт хатын тапшырды.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
**Автор фотосы.**

# ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

**Вязовый Гай авылында гомер кичерүче Суфия Миннибаевна БӘШИРОВА 15 ноябрьдә күркәм 55 яшьлек юбилеен каршы алды. Яраткан тормыш иптәшем, кадерле әнибез, сөекмеле әбекәем!**



Сине истәлекле гомер бәйрәмең белән чын күңелебездән котлыйбыз. Син балаларың, туганнарың өчен җаныңны да кызганмыйсың. Сине күреп бер сөйләшсәң, дөньялар түгәрәкләнеп, җаннар канатланып китә. Мул сыйлы өстәлләреңне, күпереп пешкән камыр ризыкларыңа, хуш исле чәйләреңә сихәтле киңәшләреңне, тәмле сүзләреңне кушып биргәнгәме, йортың нурлы, йөзең мәхәббәтле күренә. Газизебез, син беркайчан да сагыш-моңга бирешмисең, тормышны яратасың, тирә-юньдәгеләрне хөрмәтләп яшисең. Шундый гади, эчкерсез, киң күңелле булганың өчен рәхмәт сиңа, кадерлебез. Киләчәктә дә бер-беребезнең шатлыкларына куанып яшәргә, озын, тыныч гомер кичерергә язсын иде. Гомерең саулыкта, муллыкта үтсен. Һәр көнең бәхетле мизгелләрдән генә торсын. Яшәү дәртеңне сүндермичә, туасы көннәрдән тәм табып яшәсәң иде. Киләчәк көннәрең шатлык белән үтсен, гомер юлың озын, сикәлтәсез булсын. Рәхмәтләргә һәм рәхәтләргә төренеп гомер ит.



*Ходай сиңа сәламәтлек бирсен,*
*Сызламасын аяк-кулларың.*
*Чирне белмә, кайгы күрмә,*
*Ять-яшь булып калсын күңелең.*
*Әни бит ул – өйнең яме,*
*Ә тормышта олы бер терәк.*
*Сәламәт бул, озак яшә,*
*Син бит, әни, безгә бик кирәк!*

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең Мөнир Мәхмүтович, уллары Ирек, Илдус, киленең Лилия, оныгың Ислам.**

Вязовый Гай – Сызран.

**Якын кешебез, кадерле туганыбыз Суфия Миннибаевна БӘШИРОВА!**

Сине олы бәйрәмең — 55 яшьлек юбилеең белән чын күңелдән котлыйбыз, нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, балаларыңның һәм оныкларыңның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүеңне телибез. Бөтен гомереңне, көчеңне туганнарыңның бәхете өчен биргән гүзәл зат буларак әчкерсезлегең, ихласлылыгың, ягымлылыгың белән һәммәбезнең күңелен яуладың. Һәрвакытта да шулай шат, көләч йөзле, изге күңелле булып кал. Без сине чиксез хөрмәт итәбез, чын йөрәктән яратабыз. Киләчәгең җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын.



*Гомер урләрең синең кебек*
*Армый атлаучылар бик сирәк,*
*Яшәү дәртең генә сүрелмәсен,*
*Илле биштә дә безгә син терәк.*
*Туганлыкны саклап яшик шулай,*
*Бер-беребезнең хәлен белешик.*
*Шатлык килсә бергә уртаклашып,*
*Борчуларны бергә бүлешик.*

**Изге теләкләр белән каенагаң Забир, тормыш иптәше Венера, балалары белән, каенэнең Кадим, тормыш иптәше Рәшидә, уллары Айрат, киленнәре Лилия, оныклары Илнур, Данияр, Эльвина, кызлары Кадрия, каенсеңелең Зифа, тормыш иптәше Рафаэль, уллары Радик.**

Вязовый Гай – Сызран – Ульяновск – Балаково.

**Кадерле сеңелебез Суфия Миннибаевна БӘШИРОВА!**

Сине истәлекле 55 яшьлек юбилеең белән чын күңелебездән тәбриклибез. Син һәрберебезгә беренче ярдәмгә киләсең. Олы җанлы, киң күңелле, сеңелебез, рәхмәт сиңа. Саулыкның иң кадерлесен, бәхетнең иң зурысын телибез. Алдагы көннәрең бәхет-шатлыкта, кайгы-хәсрәтсез үтсен. Аллаһы Тәгалә сиңа тормыш иптәшең белән бергә тигез, матур гомерләр бүләк итсен. Балаларыңның игелеген күреп, оныкларыңа шатланып, бергә матур гомер итәргә язсын.



*Бу тормышта егылмыйча*
*Атлар өчен юлларны,*
*Һәркемгә дә кирәктер ул*
*Синең кебек туганы.*
*Кайчан керсәң, өеңдә нур бөрки,*
*Каршылыйсың якты йөз белән.*
*Кайгы-хәсрәт җиңеләеп китә*
*Синең әйткән йомшак сүз белән.*

**Иң матур теләкләр белән апаң Румия, тормыш иптәше Акбар, кызлары Венера, Галия, кияүләре Ришат һәм яраткан оныклары.**

Вязовый Гай.

**Карамалы авылында яшәүче Мәүҗүдә Низамовна ДАВЫДОВАГА 18 ноябрьдә 90 яшь тула. Газиз кешебез – сөекле, яраткан әниебез, әбекәебез!**



Әниебез олы йөрәкле, сабыр, ярдәмчел, киң күңелле, ачык йөзле кеше. Туган авылыбызда да аны һәркем бик ярата һәм хөрмәт итә. Безнең өчен үрнәк һәм бик зур терәк ул. Өебезнең - нуры, тормышыбызның - зур өлеше, һәрберебезнең нык терәге булган кадерлебез безнең. Ихлас күңелдән сине әлеге матур юбилеең белән котлыйбыз. Син янәшәбездә булганда, күңелебез тыныч, тормышыбыз имин безнең. Яныбызда синдәй игелекле, сабыр, төпле киңәшләре белән ярдәм итәрлек кешебез барында без чиксез бәхетле. Безгә биргән яхшы тәрбияң, акыллы киңәшләрең өчен бик зур рәхмәт сиңа, әни. Безгә күрсәткән игелекләрең, безгә биргән йөрәк җылың өчен алдыңа килеп, баш иеп, рәхмәт белдерәбез, кадерлебез.

*Рәхмәт синең шәфкатьтулы йөрәгеңә,*
*Рәхмәт ару-талу белмәс беләгеңә.*
*Рәхмәт хәстәр белән караган күзләреңә,*
*Юаныч һәм шатлык биргән сүзләреңә.*
*Син булганда без бик бәхетле,*
*Синең белән дөнья бик тыныч.*
*Саулык белән, шатлык белән үтсен һәр көнең.*

**Матур теләкләр белән улың Фәрит гаиләсе белән: Хадия, Эльмира-Роман, Кирилл, Артем, Руслан, Тимур; кызың Фәрүзә гаиләсе белән: Ленизa, Алексей, Радион; улың Фәһим гаиләсе белән: Сурия, Фаил, Галия, Эмиль, Амина, Реналь; улың Ринат гаиләсе белән: Рәйсә, Алина, әлеге теләкләргә сеңелләрең, энеләрең һәм аларның бала-оныклары да кушыла. Әтиебезнең (мәрхүм инде) туганнары, кода-кодачаларың, тирә-күршеләрең, авылдашларың чын күңелдән сине юбилеең белән тәбриклиләр.**

**Урта Терешка авылында гомер итүче Фәһимә Ризвановна АМИНОВА 12 ноябрьдә 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Кадерле тормыш иптәшем, яраткан әниебез һәм әбекәебез!**

Без сине 60 яшьлек юбилеең белән ихлас күңелдән кайнар котлыйбыз. Синең кебек сабыр, миһербанлы, саф күңелле әниләр бик сирәктер. Син безнең таяныч та, ышаныч та, яклаучыбыз да, саклаучыбыз да. Сиңа озын гомер, бәхет-шатлыклар, җан тынычлыгы, тән сихәте, саулык-сәламәтлек телибез. Кайгы-хәсрәткә бирешмичә, ярдәмчел, изге күңелле булып, балаларыңның һәм оныкларыңның игелеген күреп, озак яшәргә насыйп булсын. Рәхмәтләргә һәм рәхәтләргә төренеп яшә.



*Сөйкемле карашың кояшка тиң,*
*Бар тормышны нурга күмәсең.*
*Бу дөньяның барлык хикмәтләрен*
*Бары тик син генә беләсең.*
*Тормышта гел ярдәм итеп тора*
*Зирәк киңәшләрең, җылы сүзең.*
*Иркәлисең, яратасың юатасың,*
*Тынлыйсың да, аңлыйсың да үзең.*

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең Фәрит Абясович, улың Фаил, киленең Фәния, оныкларың Наргиза һәм Альмира.**

Урта Терешка – Сызран.

**Яраткан әниебез һәм әбекәем Фәһимә Ризвановна АМИНОВА!**

Кадерлебез, бу шатлыклы көнең белән сине чын күңелдән тәбрик итәбез. Син һәрвакыт безнең өчен тайпылышсыз, гадилек, кешелеклелек, матурлык үрнәге булдың. Йомшак сүзле, сөекле әниебез! Тормышыбызда киңәшчебез, ышанычлы терәк булып яшәвең - безнең өчен зур бәхет. Якты йөзең, тәмле сүзләрең өчен меңмең рәхмәт сиңа. Сиңа мөрәҗәгать иткән кешеләргә акыллы киңәшләр бирдең, игелек эшләүдән тәм таптың. Бүген син оныкларыңа - кунакчыл әби, туганнарыңа – нык терәк, бик күп санлы дусларыңа - ышанычлы дус. Киләчәгең җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарың һәрвакыт нурлы, күк йөзең һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшә!



*Кулларыңнан синең гөлләр тама,*
*Тырышлыгың бар да үзеңнән.*
*И, әнкәем, һәрчак бәхетле бул,*
*Нур сирпелсен синең күзеңнән.*
*Рәхмәт, әнкәй, тудырганың өчен,*
*Аяз көннәр булсын җаныңда.*
*"Бисмилла" дип, син шатланып уян*
*Гомереңнең һәрбер таңында.*

**Иң җылы теләкләр белән кызың Динара, киявең Марсель, оныгың Алия.**

Урта Терешка – Ульяновск.

**Мосеевка авылында гомер итүче кадерле әниебез, әбекәебез Фәһимә Рызвановна АХТӘМОВА 19 ноябрьдә гомер бәйрәмен – 80 яшьлек юбилеен билгели. Газиз әниебез, яраткан әбекәебез!**

Без сине чын күңелдән олы юбилеең белән котлыйбыз. Әниебез, Аллага шөкер, безне сөендереп, якын киңәшчебез булып, барыбызны бергә туплап, безнең арада яши, һәрберебезнең тормышы турында кайгырта. Киләчәктә дә Ходай безне бу бәхеттән аермасын. Безне, балаларыңны, сау-сәламәт итеп үстергәнең, тырышып эшләргә, кешеләрне хөрмәт итәргә өйрәткәнең өчен меңмең рәхмәт сиңа, кадерлебез! Яныбызда синдәй игелекле, сабыр, төпле киңәшләре белән ярдәм итәрлек кешебез булуга без чиксез бәхетле. Сиңа корычтай нык сәламәтлек, хәерле, бәрәкәтле гомер, күңел тынычлыгы, балаларыңның, оныкларыңның игелеген күреп, алга таба да тормыштан ямь табып, һәр туар таңга сөенеп яшәргә язсын.



*Сиңа рәхмәт сүзен, әниебез,*
*Белдерәбез туган көнеңдә.*
*Үстердең син безне кеше итеп,*
*Олы рәхмәт барысы өчен дә.*
*Бәхеткә, шатлыкка күмелеп,*
*Һәрвакыт елмаеп һәм көлеп,*
*Кадергә, хөрмәткә төренеп,*
*Яшә син мәңгелек нур булып.*

**Изге теләкләр белән улларың Рафаэль, Рүфәт, Рәфать, кызың Гүзәл, киленнәрең Алия, Рауза, Венера, киявең Илдар, оныкларың Гөлназ-Тимур, Радик, Эльвира-Руслан, Раил-Аделя, Айрат-Юля, Газинур, Алмаз һәм оныкчаларың.**

Мосеевка – Иске Кулаткы – Мәскәү – Евлейка – Тольятти – Чехов – Новоспасск.

# ЯКТАШЫБЫЗНЫ ИСКӘ АЛЫП

***Хөрмәтле районадшлар, кадерле авылдашларым! Барчабызга да билгеле булганча, безнең якташыбыз Фәһимә Билял кызы Сәйфуллина арабыздан бакыйлыкка күчте.***

Аның тормыш биографиясе, эшләгән изгелекләре, кылган ярдәмнәрен һәм башка күптәрле уңай сыйфатларын сөйләп тә, язып та бетереп булмый торгандыр. Мин бер генә мисал китереп язасым килә.

Иске Мостяк авылы Советында рәис булып эшләгәндә, (1984-1990 еллар) авыл клубына капиталь ремонт кирәк иде. Без бу бинаның идәннәрен, түбәсен һәм ягулык системасын яңага алмаштырдык. Авыл культура йортын тулаем тәэмин итәрлек җиһаз, музыка кораллары да кирәк булды. Мин Иске Мостякта Фәһимә Биляловна белән яхшы мөнәсәбәттә булганга, әлеге мәсьәлә турында аңа мөрәҗәгать иттем. Ул бу вакытта Ульяновск өлкәсенең мәдәният идарәсендә хезмәт итә иде.

Кадерле якташым мине ярты сүздән аңлап алды һәм: «Гамир, тынычлан, бар кайт, мин калган эшләрегезне үз өстемә алам»,-диде.

Озак та үтмәде, ул өлкәдән безнең авыл культура йортына 440 театраль кресло, музыкаль үзәк, сахнәгә һәм тәрәзәләргә яхшы пәрдәләр җибәрде.

Без, авыл кешеләре, моңа бик шатландык. Ремонт эшләре тәгәлләнгәч, Фәһимә Биляловна авылга килде. «Авылдашларым шул креслоларга утырып, рәхәтләнеп ял итсеннәр һәм авыл җыеннары да бирәдә, халкым өчен, файдага үтсен», диде.

Креслолар әле дә бар һәм аларга утырган саен без ихтирамлы якташыбызны искә алып яшибез.

Ул бакыйлыкка күчте, әмма аның файдалы эшләре халкым өчен яши.

Фәһимә Биляловнаның исемен мәңгеләштерү максатыннан, Иске Мостяк авылы культура йортына аның исемен бирү инициативасы белән район Башлыгы Э. Ә. Ганеев чыкты. Бу бик дөрес инициатива һәм без аны район халкы белән бергә хуплыйбыз.

Фәһимә Биляловнаның якты истәлеге безнең күңелләрдә бик озак сакланыр. Ул авылга кайтkан саен мәчеткә хәер-садакаларын бирер, догалар кылдыра иде. Зиратларыбызны тәэхекләндерүдә, акчалата ярдәм итүдә дә аның өлеше шактый зур булды. Әйтерсең лә, җәннәтләргә ирешү кузләгеннән торып яшәгән.

Аның әтисе Билял бабабыз - Бөек Ватан сугышы ветераны. Ул гомеренең ахыр чигенә кадәр авылда муллалык вазифасын башкарды. Шушы изге гамәлләре аның гаиләсенә дә зур йогынты ясаган, күрәсең.

Без, гаиләбез белән, Рәшиткә, Нуриягә, Фатыймага һәм аларның гаиләләренә сабырлык телибез. Әти-әниләре Билял бабайның һәм Нәймә апаның, Фәридә һәм Фәһимә апаларыбызның рухларын шатландырып торсыннар иде.

Мин үзем дә, гомерем бар кадәрле, аларны хәер-догаларымнан ташламам.

**Гамир ВОИНОВ.**

# ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

**Урта Терешка авылында гомер итүче Рәисә Арифовна АЗИЗОВАГА 17 ноябрьдә 80 яшь тула.**

**Иң газиз, якын кешебез – хөрмәтле тормыш иптәшем, сөекле әниебез, яраткан әбекәебез!**

Сабыр холыклы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кадерледән-кадерле кешебезне 80 яшьлек юбилее белән кайнар тәбриклибез һәм котлауларның иң кайнарын, теләкләрнең иң изгесен, рәхмәтләребезнең иң олысын җиткерәбез. Син безнең таяныч та, киңәшче дә, сердәшче дә, ышаныч та. Безгә күрсәткән игелекләрең уйлап та, әйтеп тә бетерерлек түгел. Барысы өчен дә зур рәхмәт сиңа. Алдагы көндә дә туган йортыбызның җылысын саклап, безнең шатлыкларга сөенеп яшә. Ходай Тәгалә кылган изгелекләреңне күреп, сиңа нык исәнлек, җан тынычлыгы, чиксез шатлыклар насыйп итсен.

*Күз нурыңны түктең безнең өчен,*
*Йөрәк җылың булды гел юлдаш!*
*Шатлыгыбыз арта сиңа карап,*
*Безнең өчен бәхет син булгач!*
*Һәрвакытта булдың әйнең яме,*
*Авыр чакта безгә син терәк.*
*Озак яшә, һәрчак сәламәт бул,*
*Син бит безгә бик кирәк!*



**Изге теләкләр белән тормыш иптәшең Рафият Рызванович, улларың Рөстәм, Рива, кызың Люция, киленнәрең Мәйсәрә, Наилә, киявең Наил, оныкларың, оныкчаларың һәм барча туганнарың.**

Урта Терешка – Казан – Ульяновск.

**Мосеевка авылында гомер итүче Наил Ибраһимович ҖӘЛӘЕВ 15 ноябрьдә туган көнен билгеләде.**

**Кадерле тормыш иптәшем, яраткан әтиебез һәм бабакаебыз!**

Сине чын күңелебездән туган көнең белән котлап, йөрәкләребездән чыккан иң изге теләкләребезне юллыйбыз. Безне кадерләп үстереп, яратып-сөеп, аталарча кайгыртканың, гаделлеккә өйрәткәнең өчен зур рәхмәт сиңа, әти. Син, әти, безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле кеше, таянычыбыз, ышанычыбыз, киңәшчебез, җылы кояшыбыз, рух чишмәбез булып торасың. Син бала-оныкларыңа, туганнарыңа сабырлык, изгелек, шәфкатьлелек үрнәге күрсәтеп яшисең. Рәхмәт сиңа барысы өчен дә!

*Яшәү шатлыгы син безнең өчен,*
*Яхшылыгың белән үрнәк син.*
*Авыр чакта сиңа таянабыз,*
*Безнең өчен һәрчак кирәк син.*



**Иң җылы теләкләр белән тормыш иптәшең Расимә Идрисовна, улларың Вил, Ирек, Раил, кызларың Иркә, Лилия, Римма, киленнәрең, кияүләрең, оныкларың һәм оныкчаларың.**

Мосеевка – Павловка – Иске Кулаткы – Новоспасск.

## Магазин “Квадратный метр”

Предлагает Вам бытовой линолеум “Линостар” по цене 165 рублей за квадратный метр! И большой ассортимент линолеума Таркет, Синтерос и Полистиль.

В продаже также имеется металлопрокат и огромный выбор хозяйственных товаров

Ждём Вас в по адресу: р.п. Старая Кулатка, ул. 50 лет Победы, 19, тел.: 8(927) 984-11-82; (84249) 2-28-15

## ООО «Немецкие оконные изделия»



1. Заводское производство.
2. Гарантия качества.
3. Короткие сроки.
4. Установка входных и межкомнатных дверей.
5. Выезд на замер бесплатно.

При заказе 3 окон - жалюзи в подарок
При заказе 4 окон - дверь входная в подарок.
При заказе 5 окон - шестое окно в подарок.

Рассрочка и скидки!!!

*Условия акции по тел.: 89020040102; 89374588644; 89278018665.*

*Супер акция - окно из прорфиля 70 мм. по цене окна из профиля 58 мм.*

**21 ноября в РДК с 9.00 до 17.00 часов**

**Состоится ярмарка конфет, чая из Казахстана. А также распродажа женских курток (осень -1500 руб., зима – 3000 тыс. руб), мужских и женских вязаных шапок по 200 руб.**

## ВНИМАНИЮ ЖИТЕЛЕЙ РАЙОНА!!!

**В р.п. Старая Кулатка по ул. Пионерская (рядом с магазином “Диляра”) открылся новый магазин федеральной торговой сети “Продукты Ермолино”.**

**В ассортименте: 36 видов замороженных полуфабрикатов из мяса говядины, птицы, а также колбасные, молочные, макаронные изделия.**

ЦЕНЫ ОТ ПРОИЗВОДИТЕЛЯ!!!

**Ждем Вас с 8.00 до 19.00 часов без перерыва и выходных.**

## ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА

**Производство и установка пластиковых окон.**

**При заказе пяти окон, шестое – бесплатно! Замер, доставка – бесплатно.**

*Наше качество и доступные цены порадуют вас! Пенсионерам – дополнительная скидка!*



**20% скидка**

**Телефон: 8-937-278-05-55.**
**Павловка.**

## Стоматология ООО «Дента Люкс»

**приглашает вас воспользоваться качественными услугами современной стоматологии**

**пациентам нуждающимися в протезировании готовы предложить:**

**- съемное протезирование: протезы из акриловых пластмасс, бюгельные, нейлоновые;**



**- несъемное протезирование: коронки с покрытием, металлокерамические, комбинированные, цельнолитые и.т.д.**

**Запись предварительно по тел.: 89278033404, Пионерская, 18 А. Консультация бесплатно.**

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, хезмәт ветераны **Рәхимҗан Хөсәинович АХМЕРОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының һәм туганнарының тирән кайгыларын уртаклаша.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, хезмәт ветераны **Хаернисә Хамидулловна ТИМЕРБУЛАТОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының һәм туганнарының тирән кайгыларын уртаклаша.

Безнең өчен иң кадерле, иң якын кешебез, кадерле тормыш иптәшем яраткан әтиебез һәм бабакаебыз **Каюм Шакирович АБИТОВНЫ** хөрмәтләп, соңгы юлга озатуда катнашкан, ярдәмләшкән, кайгыбызны уртаклашкан өчен мәчет картларына, төн кунучы әбиләргә, тирә-күршеләргә, туганнарга, авыл халкына чын күңелдән олы рәхмәтебезне белдерәбез. Ходай Тәгалә беркемгә дә кайгы-хәсрәт күрсәтмәсен.

**Рауза АБИТОВА.**
Иске Атлаш – Иске Кулаткы.

Безнең өчен иң кадерле, иң якын кешебез, тормыш иптәшем, әниебез, әбекәебез, җиңгиебез, апабыз **Мәсһүдә Фәтхулла кызы АБУЗЯРОВАНЫ** хөрмәтләп, соңгы юлга озатуда катнашкан, ярдәмләшкән, кайгыбызны уртаклашкан өчен Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе коллективына, мәгариф хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасына, бергә эшләгән укытучыларга, укыткан укучыларына, “Гани”, “Җәмигъ», «Әнвәр” мәчетләре картларына, авылларыбызның имамнарына, дога кылып, төн кунучы әбиләргә, туганнарга, дусларга, күршеләргә, кода-кодагыйларга, озак вакытлар дәвалаучы табибларга ихлас күңелләребездән олы рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Абузяровлар, Алиакберовлар, Бахитовлар, Богдаловлар, Арслановлар, Курбановлар, Шараповлар гаиләләре.**

**Куплю пух-перо гусиные новые, старые перины, подушки. Дорого. С выездом на дом. Телефон: 89373886444.**

**Организация реализует кур-несушек с доставкой на дом. Тел.: 89298156785.**

**Продается дом по ул. Нижне-Северная, площадь 60 кв.м. Газовое отопление. Центральное водоснабжение. Участок 27 соток. Возможен обмен на квартиру. Телефоны: 8-929-797-34-34, 8-927-833-19-99.**

**Куплю пух-перо гусиное, старые подушки, перины. Телефоны: 89066798118; 89009291857.**

**Продается “ВАЗ-21063”, 2005 года выпуска, в хорошем состоянии. Цена 40 тысяч рублей. Телефон для справок: 89278046971.**



- Окна от производителя
+ комплектующие
- Двери «Бульдорс»
- Натяжные потолки (от 240 руб./в.м)

**Телефоны: 88422(651832), 89041823507, 89374550649.**

**Старокулаткинская автомобильная школа ДОСААФ России**

ОБЪЯВЛЯЕТ НАБОР ГРАЖДАН НА ПРОФЕССИОНАЛЬНУЮ ПОДГОТОВКУ ВОДИТЕЛЕЙ ТРАНСПОРТНЫХ СРЕДСТВ:
- КАТЕГОРИИ
«А» - мотоциклы,
«М» - скутеры, мопеды,
«В» - легковые автомобили,
«С» - грузовые автомобили;
- категории «С» для Вооруженных СИЛ;
- ежегодные занятия с водителями автотранспортных организаций – 20 ч.;

Имеются:
- группы выходного дня;
- курсы восстановления навыков вождения;
- курсы экстремального вождения;
- предоставляются скидки учащимся, студентам, инвалидам, пенсионерам, временно не работающим гражданам.

КОНТАКТНЫЕ ТЕЛЕФОНЫ: (84 - 249) 2 – 14 - 39; 8 – 927 – 27 – 14 – 600, ул. Куйбышева, 42.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, хезмәт ветераны **Расим Батырханович КӘРИМОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының һәм туганнарының тирән кайгыларын уртаклаша.

Мәгариф хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасы һәм Иске Зеленай урта мәктәбе коллективы әтисе **Равил Корбанович САФАРОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, аш пешерүче Гөлсем Равилевна Сафарованың тирән кайгысын уртаклашалар.

Директор-баш редактор М.С. Масиева.

Адрес редакции, издателя: 433940 р.п. Старая Кулатка Ульяновской области, ул. Куйбышева, 22. ОАУ Редакция газеты "Кумяк кючь".

Телефоннар:
электрон адрес: kumiakk@mail.ru
884(249)2-11-94-редактор, факс, бухгалтерия;
884(249)2-12-64 - журналистлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.

Индекс 54505.
Газетаны басарга кул кую вакыты: график буенча - 16.00 фактта - 16.00
Тираж 2600
Заказ № 13/46
Распространяется по подписке.

Газета отпечатана с готового оригинала-макета в ООО «Принт Хаус» 432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.

Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль службаның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.

Газета битләренә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.

Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Хатлар, кулъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.